КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 5 февраль г.Казань № 77

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 22 ноябрь, 1041 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык күрсәтү, эшмәкәрләр мәнфәгатьләрен яклау һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, съездлар, семинарлар, стратегик сессияләр, түгәрәк өстәлләр, шулай ук комиссияләр утырышларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык күрсәтү, эшмәкәрләр мәнфәгатьләрен яклау һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, съездлар, семинарлар,

стратегик сессияләр, түгәрәк өстәлләр, шулай ук комиссияләр утырышларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 22 ноябрь, 1041 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык күрсәтү, эшмәкәрләр мәнфәгатьләрен яклау һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, съездлар, семинарлар, стратегик сессияләр, түгәрәк өстәлләр, шулай ук комиссияләр утырышларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта татар текстында «Субсидия бирү турында мәгълүмат» сүзләреннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.7 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «субсидия тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш» сүзләрен «субсидия акчасы тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш» сүзләрен «субсидия акчасы тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган хәлләр ачыкланган көннән 30 календарь көннән артмаган срокта субсидия алучыга таләп алынган көннән 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.»;

8.5 пунктта татар текстында «субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин